ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл
җирлеге Советы

422756, ТР Әтнә муниципаль районы,
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 34-6-25

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Большеменгерского
сельского поселения
Атнинского муниципального района

422756, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Большой Менгер, улица Советская, 8
тел. 34-6-25

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«25» февраль 2021 ел № 20

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 25.10.19 ел, №112 карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 110 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү:

**1.1. Нигезләмәнең 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 абзац өстәргә:**

- инициативалы проектларны тәкъдим итү , әзерләү ,сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә »;

1.2. 3. 20 пунктны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

« Әгәр гражданин җитди сәбәпләр ( сәламәтлек ,инвалидлык һ. б.) буенча гражданнар җыенында катнаша алмаса, гражданинның фамилиясе ,исеме һәм атасының исеме , аның яшәү урыны , аның гражданнар җыенында катнаша алмавы сәбәбе , шулай ук аның гражданнар җыенына чыгарыла торган үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсенә турыдан-туры мөнәсәбәте аның гаризасы нигезендә гражданнар җыенында исәпкә алына».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында , Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru ) веб – адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Ф.К.Тахавиев